КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 20 май г.Казань № 339

Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме чаралары турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 8 апрель, 235 нче карары нигезендә һәм Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүне тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:
Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга сөтчелек юнәлешендә кече фермалар төзү чыгымнары өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;
Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга товар һәм нәселле таналар, бер мәртәбә бозаулаган таналар сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;
Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга өч яшьтән өлкәнрәк бияләр асрауга чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;
Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга савым сыерларын, ана кәҗәләрне һәм бер яшьтән зуррак булган кәҗә бәтиләрен тотуга чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен;
2025 елда шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга яшь кош-корт сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен.
2. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат

технологияләре һәм элемтә министрлыгына, «Минем субсидияләр» Татарстан Республикасы мәгълүмат системасыннан файдаланып, Татарстан Республикасы авыл һәм шәһәр җирлекләренең җирле үзидарә органнарына һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга субсидияләр бирүгә заявкалар бирү мәсьәләләре буенча методик ярдәм күрсәтергә.

3. Татарстан Республикасы авыл һәм шәһәр җирлекләренең җирле үзидарә органнарына, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән берлектә, авыл яисә шәһәр җирлеге территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга субсидияләр бирү мәсьәләләре буенча мәгълүмати хезмәттәшлек турында килешү төзүне тәкъдим итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин